РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

№ 29 «15» мая **2019г.**

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү турында

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан, Татарстан Республикасы Президентының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү турында»гы 2018 елның 8 маендагы ПУ-360 номерлы Указы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019-2020 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына багышланган тантаналы чаралар үткәрергә.

2. Теләче муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба - Оештыру комитеты) төзәргә.

3. Оештыру комитеты турында Нигезләмәне (1нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. Теләче муниципаль районы башкарма комитетына:

ике ай эчендә Оештыру комитеты тәкъдимнәрен исәпкә алып, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча, аларны үткәрү срокларын, җаваплы башкаручыларны, күләмнәрне һәм финанслау чыганакларын күрсәтеп, чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына оештыру комитетлары төзүне һәм муниципаль берәмлекләрдә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм үткәрү буенча чаралар планын раслауны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф.Зарипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль
районы Башлыгының
2019 елның «15» июня 19 санлы
карарына 1нче кушымта

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 1941-1945 ЕЛЛАРДАГЫ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҖИҢҮНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮГӘ ӘЗЕРЛЕК ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Теләче муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча Оештыру комитеты (алга таба - Оештыру комитеты) Теләче муниципаль районында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына багышланган тантаналы чараларны әзерләү һәм үткәрү, шулай ук югарыда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнашучы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында оештырылды.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитеты һәм аның составы турында нигезләмә Теләче муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

4. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләрдән тора:

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү чаралары планына тәкъдимнәр эшләү (алга таба-Чаралар планы);

Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмаларның чаралар планын үтәү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшчәнлекләрен координацияләүне тәэмин итү;

Чаралар планын үтәү мәсьәләләрен карау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү.

5. Алда торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында оештыру комитеты хокуклы:

Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль учреждениеләрдән, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга ;

Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлыча эшче төркемнәр төзергә;

үз утырышларына Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар җитәкчеләрен чакырырга.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасары һәм аның эшчәнлегендә җәмәгать башлангычында катнашучы Оештыру комитеты әгъзалары керә.

Оештыру комитеты рәисе булып Теләче муниципаль районы Башлыгы тора.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

Оештыру комитеты утырышын Оештыру комитеты рәисе яисә аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары алып бара

8. Утырышларның көн тәртибен, аларны үткәрү урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

9. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

Оештыру комитеты утырышында каралган мәсьәләләр буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Оештыру комитеты карарлары Оештыру комитеты утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Оештыру комитеты утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Оештыру комитеты әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы, һәм аның фикере Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

10. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителә торган карарлар Теләче муниципаль районының кызыксынган җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждениеләргә, иҗтимагый берләшмәләргә җиткерелә.

Оештыру комитеты карары нигезендә Теләче муниципаль районы Башлыгы һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты актлары проектлары әзерләнә ала.

11. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник, документация һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне Теләче муниципаль районы Советы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль
районы Башлыгының
2019 елның «15» июнь 29 санлы
карарына 2нче кушымта

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 1941-1945 ЕЛЛАРДАГЫ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҖИҢҮНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮГӘ ӘЗЕРЛЕК ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ СОСТАВЫ

Зарипов И.Ф.	Теләче муниципаль районы Башлыгы, Оештыру комитеты рәисе;
Нурмөхәмәтов А.Ә.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Оештыру комитеты рәисе урынбасары;
Фәтхуллин А.Г.	Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары,
Миңнегулов И.Ә.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестицион эшчәнлек буенча урынбасары;
Яхин Р.Р.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе;
Гыйниятуллин И.С.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы;
Карпова Н.В.	«Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы;
Газизов М.М.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының ветераннар Советы рәисе;
Иксанов Д.С.	Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы;
Галимова Ф.М.	Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгың Теләче районындагы бүлеге начальнигы (килешү буенча);
Хуҗин Л.Й.	«Татмедиа» ААҖ филиалы «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәге директоры (килешү буенча).

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).